КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 25 апрель г.Казань № 540

Менделеевск муниципаль районында җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында

Россия Федерациясе Җир кодексы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, «Җирләрне яки җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында» 2004 елның 21 декабрендәге 172-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 9 пунктына, «Татарстан Республикасы Җир кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү турында» 2026 елның 19 февралендәге 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Менделеевск муниципаль районында урнашкан 0,5876 гектар гомуми мәйданлы авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләрен кушымта нигезендә коммуналь хезмәт күрсәтү объектларын урнаштыру максатларында сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшыру, телевидение, информатика җирләре, космос эшчәнлеген тәэмин итү җирләре, оборона, куркынычсызлык җирләре һәм башка махсус билгеләнештәге җирләр категориясенә күчерергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2026 ел, 25 апрель, 540 нчы карарына кушымта

Сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшыру, телевидение, информатика җирләре, космос эшчәнлеген тәэмин итү җирләре, оборона, куркынычсызлык җирләре һәм башка махсус билгеләнештәге җирләр категориясенә күчерелә торган җир кишәрлекләре исемлеге

| Җир кишәрлегенең кадастр номеры | Мәйданы, гектар | Муниципаль район исеме |
|---|---|---|
| 16:27:010401:5 | 0,0252 | Менделеевск |
| 16:27:030202:682 | 0,1351 | |
| 16:27:0401:1396 | 0,0936 | |
| 16:27:030201:710 | 0,3337 | |
| Барлыгы | 0,5876 | |

---